ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

"31 октябрь 2025 ел Сәмәкәй авылы № 13

**"Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының 01.11.2019 елның 42/2 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылында 2025 елның 15 нояберендә 11.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл җирлегенең Күгәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре);

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Күгәш авылы, Урман урамы, 30 нчы йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы
Совет Рәисе И. М. Усманов

СЕМЕКЕЕВСКОГО
сельского поселения